Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Болгарская средняя общеобразовательная школа № 2»
Спасского муниципального района Республики Татарстан

**Республиканская научно – практическая конференция школьников «Полилингвальное образование и межкультурная коммуникация в XXI веке»**

Секция 5

«Год родных языков и народного единства в Республике Татарстан»

# Язык-наш дар бесценный.

Шагеева Азалия Рамилевна,

8 класс МБОУ «Болгарская СОШ№2»

Руководитель: Файзиева Гузалия Рашитовна,

учитель родного (татарского)языка и литературы.

2021

**Эчтәлек**

Кереш сүз(Телнең килеп чыгышы)_____________________3-4 бит

Төп өлеш (Татар язучыларының телгә мәхәббәте) ________4-6 бит

Йомгаклау өлеше(Никадәрле кадерле ул миңа)___________ 6 бит

Кулланылган әдәбият_________________________________7 бит

# Кереш

И туган тел,и матур тел,

Әткәм-әнкәмнең теле.

Дөньяда күп нәрсә белдем

Син туган тел аркылы.

Г.Тукай

Кеше тормышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр ,әйберләр була.Мин шуларның берсе дип, туган телне саныйм. Ул – кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшә. “Туган” сүзе тагын берничә сүз белән сүзтезмә ясый: “туган ана”,”туган ил” һәм “туган тел”.Бу төшенчәләр-өчесе дә кеше өчен иң якын ,иң кадерле.

Тел –кешеләрнең үзара аралашу чарасы.Тел булмаса ,кешеләр аралаша,фикер алыша алмаслар иде.Тел шулай ук,тәҗрибә туплау,халыкның фән,мәдәният,әхлак өлкәсендәге казанышларын яңа буынга тапшыру чарасы,ягъни буыннарның аралашу чарасы да. Кешеләр һәм буыннар аралашмаса,кешелек җәмгыяте барлыкка килә алмаган булыр иде.

Безнең туган телебез- татар теле.Ул безнең милли телебез.Бу телдә Татарстанда һәм илебезнең башка бик күп республикаларында, өлкәләрендә яшәүче дистә миллионга якын татар халкы сөйләшә . Татар теле –Татарстан республикасының дәүләт теле.Без үз телебездә белем алырга ,тормышның барлык өлкәләрендә үз телебезне кулланырга хокуклыбыз.

Килеп чыгышы ягыннан,татар теле төрки телләр гайләсенә керә.Бу гайләгә тагын башкорт,казах,кыргыз,үзбәк,төрекмән,азербайҗан төрек һәм башка телләр керә.

**Төп өлеш**

Безнең туган телебез –бик борынгы һәм бай телләрнең берсе.Ул башка телләр арасында искиткеч зур сүзлек байлыгы,үзенчәлекле грамматик төзелеше белән аерылып тора.

Иң моңлы көй – милли көй,
Иң матур тел - туган тел.

Туган телең аша җирдәге,кешедәге матурлык бөтен тулылыгы белән аңлашыла.Җырларыбызга моңлылык хас булган кебек,телебезгә дә моңлылык хас.Ә моң кешенең күңел түрендә туа.Моңлы халык начар була алмый.Моң ул- халык рухының ышанычлы сакчысы.Шуны онытмасак,телебез һәрвакыт моңлы,ягымлы,аһәңле булыр.Туган тел һәр кеше өчен кадерле һәм газиз була.

Тел милләт белән бергә туа,бергә үсә һәм милләтнең иң ышанычлы,кадерле кардәше юлдашы һәм юанычы булып яши.Күп гасырлар буена телебез үскән,шомарган һәм сүзләре кыскарып җыйнакланган.Сүзләрнең кыскалыгына карап,телнең җыйнаклыгын,камиллеген һәм хәтта яшен дә чамалап була.Күрәсең татар теле бик борынгы тел булырга тиеш.

Тел галимнәре җир йезендә телләр арасыннан халыкара аралашу өчен иң аңлаешлы булган ундүрт  телне сайлап алганнар. Ул унберенче урында тора һәм төрки теле 150 миллионнан артык халыкка аңлашыла.Шуңа күрә, татар телен саклап калу татарлар өчен дә гаять әһәмиятле.

Тел күрке – сүз,милләт күрке – тел була.Тел- милләтнең бөтен яшәү гомер буе тапкан –зиһен байлыгы . Үз туган теленең кешегә тәэсир көче дә ныграк.Бу турыда аксакал язучыбыз Гомәр Бәширов бик дөрес әйткән.Ул инде туган телнең байлыгын бик яхшы белә,чөнки гомере буе халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыйган һәм өйрәнгән кеше.“Халыкның иң зур байлыгы,иң кадерле рухи хәзинәсе,-дип яза Г.Бәширов,- һичшиксез,аның теле.Халык үзенең телен,оста бакчачы кебек,яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап,мең еллар буена үстереп килгән.Өзлексез баетып ,матурлап,иң тирән фикерләрен,иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән”. Никадәр мәгънәле сүзләр!

Минем туган телем-татартеле. Шагыйрь Нажар Нәҗми аны “җырдай моңлы”,Равил Фәйзуллин “тыйнак ,басынкы,түзем”,И.Гыйләҗев “тәмле ,күркәм,өстен”,ә Хәсән Туфан исә “күкрәүләр теле,батыр һәм җәүһәр мирас “дип атыйлар.

Тел яшәсә,милләт яши,милләт яшәсә,милли горурлык яши.Татар халкы да барлык башка халыклар кебек үк,үзенең телен,моңын да белергә тиеш.Шунда гына безне башка милләт кешеләре хөрмәт итәр.Үз телен белерлек тә сәләте булмаган кешедә нинди горурлык булсын да,аңа нинди хөрмәт тусын?!

Тел тарихы ул-ил тарихы.Безнең туган телебез тарихның төрле авырлыкларына,җәзалау-кимсетүләренә дучар булган.Ләкин :

Чукындырган чагында да
Чукынмадың татар теле,-
ди Нажар Нәҗми.

Муса Җәлил,Абдулла Алиш,Х.Мөҗәйләрнең татар телендә язылган шигырьләре фашистларның тимер ишекләреннән ,гильотиналарыннан да көчле булдылар.Бу турыда шагыйрь Р.Фәйзуллин:

Түзем тел ул-

окопларда,төрмәләрдә,лагерьларда
атылса да,асылса да,
җиңү рухын җуймаган ул.
Гильотина өсләрендә
Яшәү җырын җырлаган ул!-
дип,татар теленә булган югары бәясен бирә.

## Йомгаклау

Шуның өчен без үз телебезне үзәккә куеп,шуның нигезендә ,башка телләрне өйрәнергә тиешбез. Әгәр дә без газиз балаларыбызны киләчәктә зур фән дөньясында иркен сулыш белән йөзәрлек итәсебез килсә,аларны шул халыкара ундүрт телнең кимендә икесен бик яхшы белерлек итик.Туган телен кадерләгән халык кына кадерле,абруйлы,дәрәҗәле халык була!
Шуның өчен бу байлыкны күз карасыдай саклап,киләсе буынга тапшыру һәрберебезнең изге бурычы!
Мин үземнең татар баласы булуым белән горурланам!

**Кулланылган әдәбият:**

1)Г.Тукай М. Җәлил,А.Алиш,Х.Мөҗәй шигырьләр җыентыгы;

2)Татар теленең килеп чыгышы татар теле дәреслеге 5 нче сыйныф укучылары өчен;

3)Н.Нәҗми “Татар теле” шигыре.